РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

26.06.2020 №279

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» күрсәтмәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль милекне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба – муниципаль милек) арендалау шартнамәләре буенча тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән җиде эш көне эчендә, муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү, 2020 елның апрель - июнь айлары өчен, мондый арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән вакытка, кичектерелгән аренда түләүләрен түләү срогы 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча башлану белән;

б) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге күрсәтмә үз көченә кергән көннән әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүматны урнаштыру.

2. Билгеләргә:

а) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүгә кичектереп тору бирелә;

б) әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен кичектереп торуны һәм аның тигез өлешләре белән 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда түләүне, шулай ук аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә кичектереп тору бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары,
Советы рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов